**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Манзарас авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**13 ноябрь 2020 ел** **№35**

**«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Кул авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 24 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Кул авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.
2. 2020 елның 25 ноябренә 12 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Кул авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.
3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне сайлау тәртибе (территориаль, вакытлы яки башка билге буенча) муниципаль берәмлек Башлыгының гражданнар җыенын билгеләү турындагы карарында күрсәтелә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 яки күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр яисә ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Киндер Кул авыл җирлегенең Киндер Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Киндер Күл авылы зиратын коймалау, смета документларын эшләү;
- Киндер Күл авылының урам юл челтәрен карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү;
- Киндер Күл авылында урамнарга энергия саклаучы лампалар, яктырткычлар сатып алу, урнаштыру, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү (яшелләндерү, агачларны кисү);
- Киндер Күл авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Киндер Күл авылында Энергетиклар, Яңа, Насыйбуллин, Клуб урамы юлларына вак таш җәю; торбалар сатып алу һәм сузу (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Киндер Күл авылының Клуб урамына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру, смета документларын эшләү;

- Киндеркүл авылының хоккей мәйданчын киртәләп алу өчен сетка һәм саклагыч койма сатып алу һәм урнаштыру, сметта документларын эшләү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Хәбибуллина